**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылында гражданнар җыены карары**

21.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яңа Мәртле авылында зиратны төзекләндерүгә, инвентарьны саклау өчен бина төзүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күшке авыл җирлегенең Яңа Мәртле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күшке авыл җирлеге башлыгы _________ А.В. Стрелков

Гражданнар җыены секретаре _________ Л.Г. Мусина